# Зул-Карнәйн

قصة ذي القرنين

اللغة التتارية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд
Сәрхән

ALSARHAAN.COM
MAHADSUNNAH.COM

العدل أساس المُلك ومن أعظم الملوك العادلين على مر التاريخ ذو القرنين؛

Гаделлек җитәкчелекнең асылы булып тора һәм тарихта иң бөек гадел патшаларның берсе Зүл-Карнәйн.

وسُمي بذلك لأنه بلغ أقصى الأرض شرقا وغربا وملَكَ ما بينهما

Ул җирнең иң ерак өлешенә көнчыгыштан алып көнбатышка хәтле барып җитеп шушы җирләр белән идарә иткәне өчен шулай исемләнгән.

وقد يسر الله تعالى له أسباب القوة والملك فاستثمرها وأخذ بها

Һәм ул Аллаһ биргән көч-куәт һәм хакимлек белән кулланган.

Аллаһ әйтте: "Чынлыкта, Без аны җирдә ныгыттык һәм һәрбернәрсәгә аның өчен юл ачтык ".
Һәм ул юлын дәвам итте".
(Әл-Кәһф, 84-85 аятләр)

وهذا درس في الأخذ بالأسباب مع التوكل على الله تعالى

Һәм бу – сәбәпләр кылганнан соң Аллаһка тәвәккәл кылуга дәрес булып тора.

قال النبي عليه وسلم لمن سأله عن ناقته : اعقلها

Пәйгамбәребездән ﷺ дөя турында сорагач:
"Иң элек дөяңне бәйлә, һәм шуннан соң Аллаһка тәвәккәл кыл",- дип әйткән.

وقد رحل ذو القرنين إلى أقصى الغرب إلى شاطئ المحيط فوجد قوما كفارا فخيّره الله فيهم فحكم بالعدل والحكمة.

Зүл-Карнәйн көнбатышның иң ерак өлешендә булган океанның яр буена таба юл тота һәм шунда үл көферлектә булган халыкны очрата. Аллаһ аны шул халык өстеннән гаделлек һәм хикмәт белән хакимлек итәр өчен сайлап ала.

Аллаһ Раббыбыз әйтте:
"Без золымлык кылучыларны газаплаячакбыз,ﷺ соңыннан алар Раббыларына кайтырлар һәм Ул аларны зур газапка дучар итәчәк. Әмма иман китереп изге гамәл кылучыларга иң яхшы әҗер булыр, һәм Без аларга әмеребезнең җиңелен әйтәчәкбез".
(Әл-Кәһф, 87-88 аятләр)

ثم رحل الى أقصى المشرق فوجد قوما متخلفين ليس لهم بيوت تقيهم من.

Шуннан соң ул көнчыгышның иң ерак өлешенә юл тотып анда кояштан сакланырга өйләре дә булмаган артта калган халыкны очрата.

Аллаһ әйтте:
"Ул кояш чыккан урынга барып җиткәч бу кояшның аңардан сакланырлык чара булмаган кешеләр өстеннән чыкканын күрә"
(Әл-Кәһф, 90 аят)

وهكذا آتاه الله من القوة والعلم ما بلغ به المشرق والمغرب.

Шулай итеп Аллаһ аңа көнчыгыштан көнбатышка барып җитәрлек көч-куәт һәм гыйлем бирә.

Аллаһ әйтте:
"Шулай итеп аңарда булган барнәрсәне дә гыйлем белән белеп алдык".
(Әл-Кәһф, 91 аят)

ثم سار إلى مكان بين جبلين.

Соңыннан ул ике тау арасында булган җирлеккә юнәлә.

قوم قليل الحيلة والعلم.

Һәм анда көчсез, ярдәмгә мохтаҗ һәм белемсез булган халыкны күрә.

عرضوا عليه المال ليبني لهم سدا يحميهم من خطر قبيلتي يأجوج ومأجوج. تجعل بيننا وبينهم سدا. فرفض المال لاستغنائه عنه.

Алар Яджүҗ һәм Мәджүҗ кабиләләренең явызлыгыннан саклаучы дивар торгызу өчен аңа акча тәкъдим итәләр: "Әй Зүл-Карнәйн, безнең белән алар арасында дивар булдыр". Ләкин ул акча алмады,чөнки ул акчада мохтаҗ түгел иде.

"Алар әйттеләр:
"Әй Зүл-Карнәйн, хакыйкатькә, Йәджүҗ һәм Мәджүҗ җирдә золымлык кылып йөриләр. Безнең белән алар арасында дивар торгызыр өчен салым бирикме сиңа?"
(Әл-Кәһф, 94 аят)

وطلب منهم أن يساعدوه في بناء السد بقطع الحديد.

Һәм Зүл-Карнәйн алардан шул диварны торгызыр өчен тимер ваклап алып килүләрен сорады.

فلما ساوى سور الحديد ما بين الجبلين
Тимер стена ике тау белән тигезләнгәч,

. صب عليه النحاس المذاب؛
Зүл-Карнәйн эретелгән бакырны шушы диварга агызды.

وبذلك حمى القوم من يأجوج ومأجوج.
Шулай итеп бу халыкны Йәджүҗ һәм Мәджүҗ кабиләләреннән саклап калды.

Аллаһ әйтте:
"Һәм алар бу диварга менә дә алмадылар һәм аны тишеп тә чыга алмадылар".
(Әл-Кәһф, 97 аят)

وسيبقى هذا السد إلى قبيل قيام الساعة.
حتى يأذن الله تعالى بسقوطه وخروج يأجوج ومأجوج على الناس

Һәм бу дивар Аллаһ аңа ишелеп төшергә һәм Йәджүҗ һәм Мәджүҗ кабиләләренә кешеләргә таба чыгарга рөхсәт иткәнчегә кадәр, ягъни Кыямәт көне алдына кадәр торачак.

Аллаһ әйтте:
"Зүл-Карнәйн әйтте:" Бу минем Раббымның рәхмәте, ләкин Раббымның вәгъдәсе килү белән бу дивар җимерелеп төшәчәк һәм Раббымның вәгъдәсе - хак!"
(Әл-Кәһф, 98 аят)